**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НИКОЛЬСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422627, с. Никольское,
ул. Центральная , д. 35
тел:   4-31-44

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ  МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ НИКОЛЬСКИЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
422627, Никольский авылы,
Эзэк урамы, 35 нчы йорт,
тел:   4-31-44

---

**2025елның 23 сентябре** **26 номер**

# БОЕРЫК

**16:24:050802:2429 кадастр номерлы җир кишәрлегеннән шартлы рәвештә файдалануга "кибетләргә" рөхсәт бирү мәсьәләсе буенча гавами тыңлаулар билгеләү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 39 маддәсе, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Никольский авыл җирлеге Уставы, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының 2018 елның 11 декабрендәге 26 номерлы Никольский авыл җирлеге Советы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Никольский авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмә нигезендә, җир кишәрлекләренең һәм капиталь төзелеш объектларының хокук ияләренең тормыш эшчәнлеге, хокукларының һәм законлы мәнфәгатьләренең уңай шартларын үтәү максатларында, КАРАР ИТӘМ

1.16:24:050802:2429 кадастр номерлы җир кишәрлегеннән шартлы рәвештә файдалануга "кибетләргә" рөхсәт бирү мәсьәләсе буенча гавами тыңлаулар билгеләргә.

2. Билгеләргә:

2.1 Гавами тыңлауларны үткәрү датасы һәм вакыты - 2025 елның 24 октябрь 10 00 сәгатьтә.

2.2 Үткәрү урыны - Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Никольский авыл җирлеге башкарма комитеты, адресы: 422627, Татарстан Республикасы, Лаеш муниципаль районы, Никольский авылы, Центральная ур., 35йорт.

2.3 Җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан файдалануның шартлы рәвештә рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турындагы боерык проекты буенча тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Никольский авыл җирлеге башкарма комитетына түбәндәге адрес буенча тапшырырга: 422627,

Татарстан Республикасы, Лаеш муниципаль районы, Никольский авылы, Центральная ур., 35,йорт.

2.4 Чыгыш ясау хокукы белән гавами тыңлауларда катнашуга гаризалар бирү вакыты 2025 елның 20 октябренә кадәр.

3. Әлеге карарны «Камская новь» район газетасында, Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Никольский авыл җирлегенең махсус мәгълүмати стендларында урнаштырырга**.**

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Башлык-Татарстан Республикасы**
**Лаеш муниципаль районы Никольский**
**авыл җирлеге Советы рәисе** **А.Н. Пашагин**